| | |
|---|---|
| СОВЕТ МУРАЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО **МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ** ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МӨРӘЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** КАРАР

2019 елның **30 нчы сентябре** Мөрәле авылы № 26

Гражданнар**ның үзара салым акча**ларын
**кертү** һәм **куллану мәсьәләсе буенча**
Татарстан Республикасы **Кайбыч** муниципаль
районы **Мөрәле авыл җирлегенең** Мөрәле авылында
гражданнар **җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлеге Уставының 22 нче маддәсенә туры китереп, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлеге Советы **КАРАР КАБУЛ ИТТЕ**:

1. 2019 елның 21 октябренә 13 сәг 00 минутка Мөрәле ав., Үзәк ур, 70а йорт адресы буенча урнашкан мәчет бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл жирлегенең Мөрәле торак пунктында үзара салым алып бару мәсьләләре буенча гражданнар җыенының ***беренче этабын билгеләргә.***
2. 2019 елның 23 октябренә 15 сәг 30 минутка Мөрәле ав., Маршал Жуков ур., 1 нче йорт адресы буенча урнашкан Дубрава җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең административ бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлегенең Мөрәле торак пунктында үзара салым алып бару мәсьләләре буенча гражданнар җыенының ***икенче этабын*** билгеләргә.
3. 2019 елның 25 октябренә 18 сәг 00 минутка Мөрәле ав., Үзәк ур., 45нче йорт адресы буенча урнашкан мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлегенең Мөрәле торак пунктында үзара салым алып бару мәсьләләре буенча гражданнар жыенының ***өченче этабын*** билгеләргә.
4. Гражданнар жыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының яшәү урыны урыны буенча Мөрәле авыл жирлеге территориясендә теркәлгән

һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм жирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

а) авыл жирлеге территориясен төзекләнләндерү:

-торак пунктның чүплекләре территорияләрен чистарту;

б) жирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру

- Мөрәле авылында су насосын алыштыру , моның өчен материаллар сатып алу;

- Мөрәле авылында янгын гидрантларын урнаштыру , моның өчен материаллар сатып алу;

в) жирлекнең торак пунктлары чикләрендә жирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- Мөрәле авылында юлларны норматив хәлгә китерү, моның өчен материаллар сатып алу;

- торак пункт чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту.

« РИЗА» «КАРШЫ»

5.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мөрәле авыл жирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка таратырга һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru), һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мөрәле авыл жирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Кайбыч муниципаль районы**
**Мөрәле авыл жирлеге башлыгы** **Р.Р.Зиннатуллин**